ГЛАВА САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 288 30.01.2015
№ __________ __________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен тапшыру буенча килешүләр төзү тәртибен раслау турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 бүлеге нигезендә Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен тапшыру буенча килешүләр төзү тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2015 елның 30 гыйнварындагы 288 номерлы карары белән РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен тапшыру буенча килешүләр төзү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен тапшыру буенча килешүләр төзү тәртибе (алга таба текст буенча - Тәртип) Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен тапшыру буенча килешүләр төзү тәртибен билгели.

2. Муниципаль район составына керүче аерым җирлекләрнең җирле үзидарә органнары, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә әлеге җирлекләрнең бюджетларыннан муниципаль район бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны үзләренә тапшыру турында муниципаль районның җирле үзидарә органнары белән килешүләр төзергә хокуклы.

3. Муниципаль районның җирле үзидарә органнары муниципаль район составына керүче аерым җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән, муниципаль район бюджетыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә тиешле җирлекләр бюджетларына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча үз вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны аларга тапшыру турында килешүләр төзергә хокуклы.

4. Күрсәтелгән килешүләр нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнары муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән каралган очракларда һәм тәртиптә үз матди ресурсларын һәм финанс чараларын өстәмә файдаланырга хокуклы.

5. Муниципаль район составына керүче аерым җирлекләргә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча үз вәкаләтләренең бер өлешен, муниципаль район составына керүче җирлек Советларын тапшыру өчен Саба муниципаль районы Советына район вәкаләтләрен аларга тапшыру тәкъдиме белән мөрәҗәгать итәләр. Аерым вәкаләтләрне тапшыру мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать итүченең инициаторы шулай ук Саба муниципаль районы Советы да булырга мөмкин.

6. Муниципаль районга тапшыру өчен, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирлекләрнең бер өлешен бирү өчен, җирлек вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру тәкъдиме белән, Саба муниципаль районы Советы муниципаль район составына керүче җирлекләр советларына мөрәҗәгать итә. Аерым вәкаләтләрне тапшыру мәсьәләсе буенча мөрәҗәгатьләрнең

инициаторлары булып Саба муниципаль районы җирлекләре Советлары да тора ала.

7. Вәкаләтләрне тапшыру мәсьәләләре Саба муниципаль районы Советы һәм Саба муниципаль районы составына керүче җирлекләр Советлары утырышларында карала һәм карарлар рәвешендә рәсмиләштерелә.

8. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен тапшыру буенча килешүләр әлеге вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары арасында төзелә.

9. Күрсәтелгән килешүләр билгеле бер вакытка төзелергә, аларның гамәлдә булуын туктату нигезләрен һәм тәртибен, шул исәптән әлеге өлештә күрсәтелгән бюджетара трансфертларның еллык күләмен билгеләү тәртибен, тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәк булган нигезләмәләрне, шулай ук килешүләрне үтәмәгән өчен финанс санкцияләрен күздә тотарга тиеш.

10. Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларны тапшыру максатларында, бюджет законнары нигезендә, тапшырылган вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен кирәкле акчалар карала торган район һәм җирлек бюджеты турындагы карарларга үзгәрешләр кертелә.

11. Чираттагы финанс елына район бюджетын әзерләгәндә, вәкаләтләрне тапшыру турындагы килешүләрнең гамәлдә булу срогын исәпкә алып, бюджет турындагы карарда тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга акчалар карала.

12. Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бюджеттан бирелә торган субвенцияләрне формалаштыру, санап чыгару һәм исәпкә алу Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

13. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары ай саен тигез өлешләр белән күчерелә, әмма бер үк вакытта финанс чараларының бөтен суммасын күчерергә дә мөмкин.

14. Финанс средстволарын максатчан файдаланмаган очракта, алар муниципаль берәмлек бюджетына ун көн эчендә кайтарылырга тиеш.

15. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәк булганда, түләүсез вакытлы файдалану шартнамәсе нигезендә муниципаль милек тапшырыла.

16. Түләүсез файдалану килешүе тиз арада төзелә һәм килешү гамәлдә булу срогына төзелә.

17. Вәкаләтләрне тапшырган җирле үзидарә органы тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, тапшырылган финанс чараларыннан һәм матди ресурслардан файдалану турында кирәкле мәгълүматны соратып ала.

18. Хисапларның рәвеше һәм аларны бирү тәртибе вәкаләтләрен тапшырган җирле үзидарә органының хокукый актлары белән билгеләнә.

19. Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

– Яклар килешүе буенча;

– Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, берьяклы тәртиптә.

20. Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы файдаланылмаган финанс чараларын һәм матди ресурсларны һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган мөлкәтне кире кайтара.

21. Килешүне гамәлгә ашыру белән бәйле бәхәсләр сөйләшүләр һәм башка килештерү процедуралары юлы белән хәл ителә. Бәхәсне сөйләшүләр яки килештерү процедуралары үткәрү юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнарда каралган башка тәртиптә каралырга тиеш.